ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02 декабрь 2024ел № 8022

Башкарма комитетның «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә террорчылык һәм экстремизмны профилактикалау, шулай ук террорчылык һәм экстремизм күренешләре нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яки) бетерү» муниципаль программасын раслау турында» 2022 елның 22 сентябрендәге 4954 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы Карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә террорчылык һәм экстремизмны профилактикалау, шулай ук террорчылык һәм экстремизм күренешләре нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яки) бетерү» муниципаль программасын раслау турында» 2022 елның 22 сентябрендәге 4954 номерлы Карарына (Башкарма комитетның 2023 елның 24 мартындагы 2087 номерлы, 2023 елның 7 июлендәге 5940 номерлы, 2023 елның 22 декабрендәге 12418 номерлы, 2024 елның 19 мартындагы 1725 номерлы, 2024 елның 19 апрелендәге 2475 номерлы, 2024 елның 15 августындагы 5327 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән программаны финанслауны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетында «Башка гомумдәүләт мәсьәләләре» 01.13, «Мәктәпкәчә белем бирү» 07.01, «Гомуми белем бирү» 07.02, «Балаларга өстәмә белем бирү» 07.03, «Яшьләр сәясәте һәм балаларны сәламәтләндерү» 07.07, «Мәдәният» 08.01, «Физик культура» 11.01 бүлекләре (бүлекчәләре) буенча каралган акчалар хисабына 2023 елда – 180 043,24 мең сум, 2024 елда – 184 380,02 мең сум, 2025 елда – 184 180,02 мең сум күләмендә тәэмин итәргә.»;

2) «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә террорчылык һәм экстремизмны профилактикалау, шулай ук террорчылык һәм

экстремизм күренешләре нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яки) бетерү» муниципаль программасында:

- 1 бүлектә «Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме һәм чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| «Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме һәм чыганаклары | Финанслау чыганагы | Программаны тормышка ашыру еллары | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 2023 ел мең сум | 2024 ел мең сум | 2025 ел мең сум | Тормышка ашыру чорында барлыгы мең сум |
| | Муниципаль бюджет | 180 043,24 | 184 380,02 | 184 180,02 | 548 603,28 |
| | Федераль бюджет | - | - | - | - |
| | Республика бюджеты | - | - | - | - |
| | Башка чыганаклар | - | - | - | - |
| | Барлыгы | 180 043,24 | 184 380,02 | 184 180,02 | 548 603,28»; |

- 5 бүлекнең икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2023-2025 елларга программаны финанслау күләме 548 603,28 мең сум тәшкил итә, шул исәптән программаны тормышка ашыру еллары буенча: 2023 ел – 180 043,24 мең сум, 2024 ел – 184 380,02 мең сум, 2025 ел – 184 180,02 мең сум.»;

- 8 бүлекнең 11 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | Муниципаль бюджет | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «11. | Аерым затка яки затлар төркемнәренә карата нәфрәт һәм дошманлык уяту, шулай ук раса, милләт һәм дингә мөнәсәбәт билгеләре буенча кешелекнең абруен түбәнсетү билгеләренә ия булган мәгълүмати материалларга психологик-лингвистик экспертизалар һәм тикшеренүләр үткәрүне оештыру | Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе | ел саен | бирелгән экспертизалар үтәлеше, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 500,0 | 700,0 | 500,0 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Барлыгы: | 180 043,24 | 184 380,02 | 184 180,02». |

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның граждannар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе мөдире Р.К. Шипеевага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Ф.Ш. Салахов